КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1268

Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү турында

Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтүне көчәйтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга Татарстан Республикасында «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән балалар өчен яшәү минимумы зурлыгының 50 проценты күләмендә айлык акчалата түләүне фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән датага билгеләргә.

2. Карарга теркәлгән Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирү тәртибе турында нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирү эшен оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасын эшләп бетерүне тәэмин итәргә.

5. Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

6. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа»

дәүләт мәгълүмат системасында фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирү турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә. Әлеге мәгълүматны «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны (аннан алуны) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырырга.

7. Әлеге карар, карарның рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә торган 4 пунктыннан тыш, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 декабрь, 1268 нче
карары белән расланды

Фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү бирү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә фенилкетонурия белән авыручы инвалид балаларга айлык акчалата түләү тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба тиешенчә - айлык акчалата түләү, инвалид бала).

2. Айлык акчалата түләү инвалид бала яшәгән ата-ананың (законлы вәкилләрнең) берсенә (алга таба - мөрәҗәгать итүче) билгеләнә.

3. Айлык акчалата түләүне билгеләү өчен мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүче вәкиле «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча бүлегенә (алга таба - Үзәк бүлеге) түбәндәгеләрне тапшыра:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза;

инвалид балада фенилкетонурия булу турында медицина белешмәсе;

чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык күчермәсен һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен (тиешле актны чит дәүләтнең компетентлы органы теркәгән очракта);

мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта ышанычнамә.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкиле Үзәк бүлегенә гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклый торган документны күрсәтә һәм мөрәҗәгать итүченең банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счеты реквизитларын тапшыра.

4. Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып электрон рәвештә, айлык акчалата түләү бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге белешмәләрне ала:

яшәү урыны буенча гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

балага инвалидлык билгеләү факты турында;

опека (попечительлек) билгеләү турында;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында.

5. Үзәк бүлеге барлык кирәкле документлар белән айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза алган көннән алып 10 эш көне эчендә айлык акчалата түләү билгеләү турында йә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән карар турында хәбәр итә.

6. Ай саен акчалата түләү билгеләүдән баш тарту яисә айлык акчалата түләү бирүне туктату турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

инвалид баланың тулысынча дәүләт тәэминатында булуы;

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителүе йә инвалид балага карата суд карары буенча аны ата-ана хокукларыннан чикләү;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

гражданның бу Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) аны алу хокукына ия инвалид баланың үлеме;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яисә) инвалид баланың Татарстан Республикасыннан читтә даими яшәү урынына күченүе;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан айлык акчалата түләү алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру фактын ачыклау.

7. Айлык акчалата түләүне бирү айлык акчалата түләүне бирү туктатуга китерә торган шартлар барлыкка килгән айдан соң килә торган айдан башлап туктатыла.

8. Мөрәҗәгать итүче айлык акчалата түләү бирүнең туктатылуына китерә торган хәлләр барлыкка килгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Үзәк бүлегенә шундый хәлләр турында хәбәр итәргә тиеш.

9. Мөрәҗәгать итүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар булган документларның чынлыгы өчен җаваплы.

Айлык акчалата түләүнең нигезсез алынган суммасын кире кайтару мөрәҗәгать итүче тарафыннан ирекле рәвештә башкарыла, ә мөрәҗәгать итүче ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, нигезсез рәвештә алынган суммалар Россия Федерациясе законнары нигезендә түләтелә.